**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЮГАРЫ АКХУҖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАРЫ

15 ноябрь, 2021 ел № 12

**Агач һәм куаклар кисүгә, кәүсәләндерүгә яки утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында Югары Акхуҗа авыл җирлеге башкарма комитеты карар итте:

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Югары Акхуҗа авыл җирлеге башкарма комитетының «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2020 елның 10 августындагы 5 карары белән расланган агач һәм куакларны кисүгә, кәүсәләндерүгә яисә утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.4 пунктның икенче баганасының беренче юлында «13 эш көне» сүзләрен «10 (ун) календарь көн» сүзләренә алмаштырырга;

2) 3.5.2 пунктының бишенче абзацында «ике эш көне» сүзләрен «бер эш көне» сүзләренә алмаштырырга;

3) 3.6.1 пунктының икенче абзацында «ике эш көне» сүзләрен «бер эш көне». сүзләренә алмаштырырга

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә) һәм авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Татарстан Республикасы**
**Апас муниципаль районы**
**Югары Акхуҗа авыл җирлеге башлыгы З.Я.Юзеев**